КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 март г.Казань № 182

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составындагы индикаторлар мониторингы өчен күрсәткечләр составын һәм аларны тапшыру ешлыгын раслау турында» 2022 ел, 21 июнь, 592 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составындагы индикаторлар мониторингы өчен күрсәткечләр составын һәм аларны тапшыру ешлыгын раслау турында» 2022 ел, 21 июнь, 592 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 декабрь, 1346 нчы, 2023 ел, 2 май, 558 нче, 2023 ел, 28 июнь, 758 нче, 2023 ел, 23 ноябрь, 1499 нчы, 2024 ел, 7 май, 314 нче, 2025 ел, 19 июнь, 442 нче, 2025 ел, 24 декабрь, 1134 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составындагы индикаторлар мониторингы өчен күрсәткечләр составын һәм аларны тапшыру ешлыгын, республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составында индикаторлар кураторлары исемлеге раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составындагы индикаторларны мониторинглау өчен күрсәткечләр составы һәм аларны тапшыру ешлыгы;

республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составында индикаторлар кураторлары исемлеге.»;

әлеге карар белән расланган Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составындагы индикаторлар мониторингы өчен күрсәткечләр составында һәм аларны тапшыру ешлыгында:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» бүлегенең «Дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә идарә итү (04.07)» бүлекчәсенең 5 пунктын түбәндәгечә редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «5. | Ирекleләр һәм җәмәгатьчелек эшчәнлегенә җәлеп ителгән яшьләрнең өлеше, процент | ел-лык | Индикаторны исәпләү методикасы Яшьләр эшләре буенча федераль агентлыкның «Яшьләр һәм балалар» илкүләм проектының «Ирекле һәм иҗти-магый эшчәнлеккә җәлеп ителгән яшьләр өлеше» күрсәткечен исәпләү методикасын раслау турында» 2024 елның 13 декабрендә 501 номерлы боерыгы белән расланган | Еллык (13 апрельгә кадәр) | Татарстан Республикасы Яшьләр эш-ләре министр-лыгы»; |

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы» бүлегенең «Объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә (01.05.03)» бүлекчәсенең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «3. | Торак һәм торак булма-ган күчемсез милекне фай-далануга тапшыру күләме, млн.кв.метр | ел-лык | Индикаторны исәпләү методикасы «Россия Федерациясе Хөкүмә-тенең «Россия Федера-циясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе | Еллык (15 апрельгә кадәр) | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында»« 2025 елның 28 гыйнварындагы 58 номерлы карары белән расланды | | |

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы» бүлегенең «Транспорт һәм юл комплексларын идарә итү (03.03)» бүлекчәсендә:бүлекчәсендә бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «1. | Эре шәһәр агломерацияләре һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары (автомобиль юлларының терәк челтәренә кертелгән юлларны да кертеп) нормативларга туры килгән өлеше, процент | еллык | Индикаторны исәпләү методикасы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 58 номерлы карары белән расланды | еллык (15 апрельгә кадәр) | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы»; |

түбәндәге эчтәлекле 52 пункт өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «$5^2$. | Агломерация ләрдә һәм шәһәрләрдә нормативтан искермәгән эксплуатация | еллык | Индикаторны исәпләү методикасы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи | еллык (1 мартка кадәр) | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы»; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | срогына ия булган җәмәгать транспорты паркы өлеше, процент | | затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында»« 2025 елның 28 гыйнварындагы 58 номерлы карары белән расланды | | |

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы” бүлегенең “Төбәк контроле (күзәтчелеге) төрен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре” бүлекчәсенең 11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Социаль-икътисадый программалаштыру (01.01) | | | | | |
| 1. | Тулаем төбәк продуктның физик күләме индексы, процент | ел-лык | статистик мәгълүматлар | еллык (хисап чорыннан соң 60 нче көнгә) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 2. | База елына карата (база 2020 ел) ха-лыкның реаль җан башына акчалата кеременең үсеш темпы (үсеш индексы), процент | ел-лык | Индикаторны исәпләү методикасы «Россия Федерациясе Хөкүмә-тенең «Россия Феде-рациясе субъектла-рының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектла-рының башкарма ор-ганнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварын- | еллык (апрельнең икенче декадасы)* | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы/ Дәүләт статис-тикасы феде-раль хезмә-тенең Татар-стан Респуб-ликасы буенча территориаль органы (киле-шү буенча) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | дагы 58 номерлы карары белән расланды | | |
| 3. | Тулаем төбәк продуктында төп капиталга инвестицияләр өлеше, процент | ел-лык | $V = \frac{A}{B} \times 100,$ монда: А – финанслауның барлык чыганаклары исәбеннән төп капиталга инвестицияләр күләме, хисап чорында үсә барган нәтиҗә белән, сум; В – тулаем төбәк продукты күләме, хисап чорында үсә барган нәтиҗә белән, сум. «Финанс булмаган активларга инвестицияләр турында мәгълүматлар» федераль статистика күзәтүенең П-2 номерлы формасы буенча исәпләнә | еллык (мартның өченче декадасы) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы/ Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) |
| 4. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектының бер хезмәткәренә исәпләгәндә керемнең үсеш темпы (2023 база елына карата), процент | ел-лык | Индикаторны исәпләү методикасы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 58 номерлы карары белән расланды | еллык (31 июльгә кадәр) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы/ Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) |
| 5. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары категорияlә- | ел-лык | Индикаторны исәпләү методикасы Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының | еллык (31 июльгә кадәр) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | рен билгеләү өчен иң чик күрсәткечләрне арттырган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өлеше (микро-, кече, урта), процент | | «Нәтиҗәле һәм конкурентлы икътисад» илкүләм проектының «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» федераль проектының КУЭ субъектлары категорияләрен (микро-, кече, урта) билгеләү өчен иң чик күрсәткечләрне арттырган КУЭ субъектлары өлеше» күрсәткечен исәпләү методикасын раслау турында» 2024 елның 31 октябрендәге 688 номерлы боерыгы белән расланды C:\home\MEP_RT\kovaljova2\Загрузки\{КонсультантПлюс} - _blank | | |
| Инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11) | | | | | |
| 6. | Сәнәгать житештерүенең гомуми күләмендә инновацион продукция өлеше, процент | еллык | $V = \frac{A}{B} \times 100,$ монда: A – инновацион продукция күләме, млн.сум; B – гомуми сәнәгать житештерү күләме, млн.сум. «Оешманың инновацион эшчәнлеге турында мәгълүмат» 4-инновация номерлы федераль статистика күзәтүе формасы буенча исәпләнә (еллык) | еллык (ноябрьнең беренче декадасы) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы/ Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) |
| Социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1) | | | | | |
| 7. | Мәгълүмат материалларының гомуми саныннан срокта тапшы- | квартал | $V = \frac{A}{B} \times 100,$ монда: A – социаль-икъти- | квартал | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы»; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | рылган мәгъ-лүмат матери-аллары өлеше, процент | | садый мониторинг нәтиҗәләре буенча вакытында тапшырыл-ган мәгълүмат матери-аллары саны, берәмлек;<br>В – социаль-икъти-садый мониторинг нәтиҗәләре буенча гомуми мәгълүмат материаллары саны, берәмлек | | |

«Гомуми индикаторлар» бүлегендә:

1 пунктның 4 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Индикаторны исәпләү методикасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру турында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык доклад формалаштыру кагыйдәләрен раслау турында» 2025 ел, 8 декабрь, 1058 нче карары белән расланган»;

11 пунктның 4 графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Индикаторны исәпләгәндә Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының аерым сатып алулары (противогазлар, халыкка хәбәр итү системасын тоту һәм җиһазлау, индивидуаль яклау чараларына хезмәт күрсәтү, аларны контрольдә тоту һәм тикшерү өчен җайланмалар, җиһазлар, радиация һәм химик контроль чаралары, су асты җиһазлары һәм кораллары) исәпкә алынмый»;

19 пунктның 4 графасындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«С – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы тарафыннан расланучы 2023 - 2025 елларга республика башкарма хакимияте органнарының өземтәләр китерә торган мәгълүмат индексының хисап кварталы өчен уртача арифметик индексына мөнәсәбәте буларак исәпләнелә торган өземтәләр коэффициенты (өземтәләр коэффициентының максималь әһәмияте 100 балл тәшкил итә. Әгәр алынган әһәмият 100 баллга тигез яисә артык булса, өземтәләр коэффициенты 100 баллга тигез билгеләнә).»;

әлеге карарга республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составында индикаторлар кураторлары исемлеген өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 21 июнь, 592 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 7 март, 182 нче карары редакциясендә)

Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә йөкләмә составында индикаторлар кураторлары исемлеге

| Т/с | Индикатор исеме | Индикаторны кураторлык итүче орган исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Квартал индикаторлары | | |
| 1. | Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең планлы күрсәткечләрен үтәү, процент | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| 2. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 апрель, б-700 нче боерыгы нигезендә министрлыкка беркетелгән предприятиеләрнең гомуми санында зыянга эшләүче предприятиеләр өлеше | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 3. | Илкүләм проектларның төбәк өлешен тәшкил иткән параметрларга ирешү дәрәҗәсе, процент | |
| 4. | Республика башкарма хакимият органы тарафыннан персонификацияләнгән йөкләмәләр, шул исәптән «Ачык Татарстан» системасында вакытында яңартылган хисаплар өлеше, процент | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы / Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы |
| 5. | Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары тарафыннан үтәү өчен контрольдә тоту срогы билгеләнгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча йөкләмәләрнең гомуми | Татарстан Республикасы Рәисенең Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе |

<table>
<tr><th>1</th><th>2</th><th>3</th></tr>
<tr><td></td><td>күләмендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча әлеге затларның республика башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән срокларда башкарылган йөкләмәсе өлеше, процент</td><td></td></tr>
<tr><td>6.</td><td>Регламент срокларында килештерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары проектлары өлеше, процент</td><td>Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы</td></tr>
<tr><td>7.</td><td>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына кергән, «Заявка хәл ителде» статусы бирелгән заявкалар өлеше, процент</td><td rowspan="2">Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы / Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил</td></tr>
<tr><td>8.</td><td>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында карау срогын 10 көннән артыкка бозу факты белән хәбәрнамәләр булу, процент</td></tr>
<tr><td>9.</td><td>Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гомуми күләмендә Татарстан Республикасы законнары чыгарылуга (кабул ителүгә) бәйле рәвештә эшләргә һәм чыгарырга (кабул итәргә) таләп ителә торган (законга караган норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан законга караган норматив хокукый актлар проектларыннан тыш), республика башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән срокларда чыгарылган (кабул ителгән), шулай ук алар тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелгән Татарстан Республикасының законга нигезләнгән норматив хокукый актлары проектлары өлеше, процент</td><td>Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы</td></tr>
<tr><td>10.</td><td>Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон рәвештә хезмәтләр күрсәтелгәндә регламент срогы бозылмыйча күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре өлеше, процент</td><td>Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы</td></tr>
</table>

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 11. | Массакүләм социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләренең гомуми санында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып, дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләргә шәхсән бармыйча, электрон рәвештә мондый хезмәтләр күрсәтүдән файдалану өчен мөрәҗәгатьләр өлеше, процент | |
| 12. | Контроль-күзәтчелек чаралары һәм профилактик визитларның гомуми санында профилактика визитлар өлеше, процент | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 13. | Контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр һәм үтенечнамәләр саны, берәмлек | |
| 14. | Планнан тыш тикшерүләрнең гомуми күләмендә куркыныч индикаторлары (ачыкланган бозулар белән) буенча тикшерүләр өлеше, процент | |
| 15. | «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасының контроль (күзәтчелек) органнары карарларына судка кадәр шикаять бирү системасына тоташкан муниципаль берәмлекләр (авыл җирлекләрен дә кертеп) өлеше | |
| 16. | Дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге, балл | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| Еллык индикаторлар | | |
| 1. | Җаваплы башкаручы тарафыннан дәүләт программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, процент | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 2. | Дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлелек дәрәҗәсе, процент | |
| 3. | Төзелгән контрактларның гомуми кыйм-мәтендә сатып алуларның башкарылмаган | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | конкурент ысуллары нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактлар кыйммәте өлеше (ведомство буйсынуындагы оешмаларны исәпкә алып), процент | комитеты |
| 4. | Сатып алуларның җыелма еллык күләменнән кече эшмәкәрлек субъектларында һәм коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларда урнаштырылган сатып алулар өлеше (ведомство буйсынуындагы оешма-ларны исәпкә алып), процент | |
| 5. | Үткәрелгән конкурент сатып алуларның гомуми күләмендә (ведомство буйсынуын-дагы оешмаларны исәпкә алып), кече эшкуарлык субъектлары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар белән үткәрелгән сатып алулар өлеше, процент | |